ГЛАВА БУРНАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
БОРНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

17.10.2022 3

с. Татарское Бурнашево

Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлегенең Юматово авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 30 октябренә Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлегенең Юматово авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2023 елда Борнаш авыл җирлеге Юматово авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500 сум күләмендә үзара салым җыюга һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә сез риза булырсызмы:

- Юматово авылында юлларны ремонтлау өчен, товарны китерү өчен билгеләнгән пунктка кадәр илтеп җиткерүче хисабына вак таш сатып алу

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Чиркәү бинасы янында халык җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Юматово авылы, Елга аръягы урамы, 39 йорт 09.00 сәгатьтә.

4. Борнаш авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Борнаш авыл җирлеге башлыгы С. В. Бурукин